

Жиденче чакырылыш МР Дәvләт Со-ветынын беренче сессиясе утырышында Мордовия Республикасы Башлыгы Артём Алексеевич Здуновнын vз вазыйфасына керешvе булды. Сайлаулар нәтижәләрен МР Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Александр Косов игълан итте. Артём Здунов 78,26% тавыш жыеп жинv яулады. Мордовия Республикасы Башлыгын вакытыннан алда сайлаулар узды һәм гамәлдә дип танылды. Артём Алексеевич Здунов халыкка, РФ Конституциясенә һәм МР Конституциясенә тугрылык турында ант бирде: «Мордовия Республикасы Башлыгы вәкаләтләрен га-мәлгә ашырганда кеше һәм граждан хокук-ларын һәм ирекләрен хөрмәт итәргә һәм сакларга, Россия Федерациясе Конституциясен, Федераль законнарны, Мордовия Республикасы Конституциясен, Мордовия Республикасы законнарын vтәргә, мина йөкләнгән бурычларны намус белән vтәр-гә, Россия Федерациясе халкына тугры хезмәт итәргә». РФ Конституциясе һәм МР Конституциясе нигезендә Артём Алексеевич Здунов Мордовия Республикасы Башлыгы вазыйфасына кереште.

Котлау сvзе белән ана һәм жыелганнарга Россия Президентынын Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле Игорь Комаров мөрәжәгать итте.

«Хөрмәтле Артём Алексеевич, сезне Мордовия Республикасы Башлыгы вазыйфасына керешvегез белән котлыйм. Сезнен югары һөнәри осталыгыгыз, энергиягез һәм эшкә сәләтлелегегез кыска вакыт эчендә сайлауларда vз ярдәмен кvрсәткән төбәк халкынын кvпчелегенә ышаныч белдерергә мөмкинлек бирде. Мин ышанам ки, сезнен торле субъектларда кvпьеллык эш тәжрибәгез, шулай ук профессиональлегегез Мордовияне vстерvдә югары нәтижәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк. Биредә житди сәнәгать потенциалы, заманча югары технологияле авыл хужалыгы, социаль олкә vсеш алган. Командагызнын грамоталы һәм тәвәккәл гамәлләре һәм регион халкынын зур ярдәме сезгә vлчәvле карарлар кабул итәргә һәм республика потенциалын кешеләр файдасына кулланырга мөмкинлек бирәчәк.

Якындагы 5 елда хакимият органнары-нын топ бурычы - кешеләрнен тормышы яхшырак һәм унайлырак булсын очен барысын да эшләv. Топ кочләрне РФ Президенты куйган масштаблы бурычларны хәл итvгә, шул исәптән Россия һәм төбәкләр vсешенен милли максатларына ирешvгә юнәлдерергә кирәк. 17 сентябрьдә Владимир Путин Мордовиянен социаль-икътиса-ди vсеше буенча йөкләмәләр исемлеген раслады. Аларны гамәлгә ашыру регион-нын дәvләт бурычы белән проблемаларны хәл итvгә, икътисаднын реаль секторын vстерv очен остәмә мөмкинлекләр булдыруга, кешеләрнен тормыш-конкvрешен яхшырту очен, хакимият органнарынын, федераль структуралар вәкилләренен, төбәк житәкчелегенен һәм жирле vзидарәнен уртак нәтижәгә эшләвенә ярдәм итәчәк. Мин сезгә, Артём Алексеевич, яна вазый-фада уңышлар, ә Мордовиягә –

vсеш һәм чәчәк атуын телим», - диде Игорь Комаров.
Россия Федерациясе сенаторы, Федерация Советынын Халыкара эшләр буенча комитеты рәисенен беренче урынбасары Сергей Кисляк ассызыклаганча, анын очен инаугурация процедурасында катнашу - зур дәрәжә. Ул РФ Федерация Советы Рәисе Валентина Матвиенконын сәламләv хатын укыды.
«Сезгә Мордовияне торле яклап vстерv буенча катлаулы мәсьәләләрне хәл итәргә, республиканын социаль-икътисади, фәнни һәм мәдәни потенциалын тормышка ашырырга ярдәм итәргә кирәк. Сезнен бетмәс- токәнмәс энергиягез һәм тулы коч белән эшли белvегез бу югары дәvләт вазыйфасында нәтижәле эшчәнлеккә ярдәм итәр, дип ышанам», -  диелә морәжәгатьтә.
Залда жыелган кунаклар алдында чыгыш ясаганда, Артём Здунов кvрсәтелгән ышаныч һәм ярдәм очен, шулай ук ил житәкчелегенә республика vсеше мәсьәләләрен хәл итvдә анлаулары очен рәхмәт белдерде.
«Россия Федерациясе Президенты Владимир Владимирович Путинга ышаныч белдергәне, туган жиремдә эшләv момкинлеге биргән очен аерым рәхмәт сvзләрен житкерәсем килә. Бу эш һәм беренче казанышлар нигезендә - анын ягыннан зур ярдәм. Мордовия Республикасы башлыгы вазыйфасына керешv - ул зур дәрәжә һәм жаваплылык, барыннан да элек, тобәк халкы алдында», - диде Артём Алексеевич.
«... Ходай ярдәме белән! Бары тик бергә һәм алга гына! Рәхмәт», - дип морәжәгать итте залга һәм тамашачыларга Мордовия Республикасы Башлыгы Артём Алексеевич Здунов.